ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ УЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАР

№ 19 14 март 2016 ел

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлегендә гражданнарга шәхси торак төзелеше һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелә торган җир кишәрлекләренең чик күләме турында

«Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 5 пунктына, Россия Федерациясе Җир кодексына, Татарстан Республикасы Җир кодексының 34 статьясына ярашлы рәвештә, Аксубай муниципаль районы Иске Узи авыл җирлеге Советы карары:

1. Гражданнарга муниципаль милектә булган җирләрдән милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең чик (минималь һәм максималь) күләмнәрен һәм дәүләт милке хокукы чикләнмәгән җирләрне билгеләргә:

0,04 гектардан 0,2 гектарга кадәр мәйданлы шәхси торак төзелеше өчен;

- 0,15 гектардан 0,5 гектарга кадәр шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен.

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга района:http:aksubaevo.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Узи авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Н.В.Айдова